| ГЛАВА<br>Бимского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Бима авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.10.2022 Бима авылы № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Бима торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге башлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Бима торак пунктында гражданнарның үзара салымы чараларын куллануны кертү мәсьәләсе буенча 2022 елның 11 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта беренче этапны билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Бима торак пунктында гражданнарның үзара салымы чараларын куллануны кертү мәсьәләсе буенча 2022 елның 11 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта икенче этапны билгеләргә.
3. Яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә:

-1 этап: Бима авылының Ленин урамы, К. Маркс урамы, Хезмәт урамы, М. Горький урамы халкы.

-2 этап: Бима авылының Нагорная урамы, Совет урамы, Пролетар урамы, Мәктәп урамы, Яшьләр урамы.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: «2023 елда Бима авыл җирлегенең Бима торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлардан, студентлардан, көндезге формада белем алучы затлардан, Россия армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм иректән мәхрүм итү урыннарында булган затлардан тыш, 500 сум күләмендә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча

җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юллап, үзара салым чараларын кертүгә сез риза булырсызмы?»:

1. Бима торак пунктындагы Пролетар, Мәктәп, М.Горький урамнары өчен вак таш сатып алу һәм юлларны каплау (сатып алу һәм урнаштыру). Килешү буенча эш өчен түләү;

2. Бима торак пунктында үләннәр һәм чүп үләннәрен чабу (дизель ягулыгы һәм май алу);

3. МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү(урамнарны кардан чистарту, дизель ягулыгы һәм май, запчастьләр сатып алу). Килешү буенча эш өчен түләү;

4. Бима торак пунктында халыкны су белән тәэмин итү (ремонтлау, хезмәт күрсәтү, су белән тәэмин итү өчен башка материаллар сатып алу);

5. Янгын автомашинасын тоту, ремонтлау. Килешү буенча эш өчен түләү;

6. Бима торак пунктында урамнарны яктырту өчен лампалар һәм фонарьлар сатып алу, урнаштыру. Электрикка килешү буенча түләү;

7 Бима торак пунктында бензин триммеры өчен запчастьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу. Килешү буенча түләү;

8. МТЗ-82 тракторы өчен асылмалы җиһазлар сатып алу (алгы төягеч һәм әйләндергеч чапкыч);

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Халык җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Бима авылы, Ленин урамы, 1 нче йорт, авыл мәдәният йорты адресы буенча үткәрергә.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы А.Г. Ишпаев